ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20.04.2018 Казан ш. № 5-2/тэ

Кулланучыларга «Ремонтно-сервисная служба-Комфорт» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан бирелә торган җылылык энергиясенә (куәтенә) тарифлар билгеләү турында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя кую турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Тарифлар буенча федераль хезмәтнең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салына торган бәяләрне (тарифларны) исәпләп чыгару буенча методик күрсәтмәләрне раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты карары нигезендә Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Кулланучыларга «Ремонтно-сервисная служба-Комфорт» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан бирелә торган җылылык энергиясенә (куәтенә) тарифларны әлеге карарга кушымтада каралган календарь бүленеш буенча билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар карар үз көченә кергән көннән башлап 2018 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасының
Тарифлар буенча
дәүләт комитетының
2018 елның 20 апрелендәге 5-2/тэ
номерлы карарына кушымта

Кулланучыларга «Ремонтно-сервисная служба-Комфорт» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан бирелә торган җылылык энергиясенә (куәтенә) календарь бүленеш буенча тарифлар

| № т/б | Муниципаль берәмлекнең, җайга салына торган оешманың исеме, тариф төре | Ел | Су | Иң көчле басымлы пар | | | | Коры һәм көчсезләнделгән пар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 1,2 алып 2,5 кг/см$^2$ кадәр | 2,5 алып 7,0 кг/см$^2$ кадәр | 7,0 алып 13,0 кг/см$^2$ кадәр | - 13,0 кг/см$^2$ күбрәк | |
| | Биектау муниципаль районы | | | | | | | |
| 1 | «Ремонтно-сервисная служба-Комфорт» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | | | | | | | |
| 1.1 | Тоташу схемасы буенча тарифлар бүлеп каралмаган очракта, кулланучылар өчен | | | | | | | |
| | бер ставкалы, сум/Гкал | карар үз көченә кергән көннән алып - 2018 елның 30 июненә кадәр | 1594,57 | - | - | - | - | - |
| | | 2018 елның 1 июленнән алып 2018 елның 31 декабренә кадәр | 1658,17 | - | - | - | - | - |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тарифларны кабул итүне оештыру,
тикшерү һәм документлар белән тәэмин итү бүлеге